**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ СӘФӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423748, Иске Сэфэр авылы,
М.Вахитов ур., 16 нчы йорт.
Тел.3-44-55

**СОВЕТ СТАРОСАФАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423748, село Старое Сафарово,
ул. М.Вахитова ,дом 16 , Тел. 3-44-55

КАРАР РЕШЕНИЕ

от 17.12.2021г. № 29

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 17 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеше), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Иске Сәфәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге Советының, 2014 елның 20 ноябрендәге 17 номерлы «Җир салымы турындагы» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләренең милек хокукындагы яисә муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләреннән даими сроксыз файдалану хокукындагы объектлардан тыш, мәгариф, фән, физик культура һәм спорт, сәнгать объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 1,5%;».

1.2. 2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге12 нче абзац белән тулыландырырга:

«-сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,6%».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Иске Сәфәр авылы, М.Вахитов урамы, 16 нче йорт; Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, адреслары буенча, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы, Иске Сәфәр авыл җирлеге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Иске Сәфәр авыл җирлегенең рәсми сайтында», «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет-телекоммуникация челтәрендәге бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Иске Сәфәр авыл җирлеге
Советы рәислек итүчесе А.К.Гиздуллин